# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге составына керүче Олыяз торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнарҗыены нәтиҗәләре турында

№ 12 «17» октябрь, 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчестатьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз торак пунктында 2022 елның «17» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Олыяз торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Олыяз торак пунктында Тукай урамындагы юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Олыяз торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Олыяз торак пунктына урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 315 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 190кеше, 60,3% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясеөчен 190 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ»позициясеөчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз торак пунктындатүбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныргa:«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Олыяз торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Олыяз торак пунктында Тукай урамындагы юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Олыяз торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Олыяз торак пунктына урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

3. Әлеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Я.Хаев